**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 11 июнендәге 1818 номерлы карары**

# Казан шәһәренең Мәскәү районында ачык сервитут билгеләү турында

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитутның характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 2190 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары: 16:50:200106:876, 16:50:200106:1511, 16:50:200106:826, 16:50:000000:5481, 16:50:200106:196, 16:50:200106:85;

- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталы: 16:50:200106;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Мәскәү районы;

- билгеләү максаты: «ТР, Казан шәһәре, Восстание урамы, 100 йорт адресы буенча кадастр номеры 16:50:0106:955 булган җир кишәрлеге чигенә кадәр газүткәргечнең тармаклануы» газ белән тәэмин итү системасының линия объектын төзү һәм эксплуатацияләү өчен;

- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүче: «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

1.3. билгеләүгә нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясының 1 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы «Газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Казан шәһәр Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре округының генераль планы, Россия Федерациясе Президенты

В.В.Путин йөкләмәсе нигезендә, гражданнарның акчаларын җәлеп итмичә, газлаштырылган пунктларда җир кишәрлекләре чикләренә кадәр газ кертү программасы.

2. Әлеге карарның 1 номерлы һәм 2 номерлы кушымталарында күрсәтелгән җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт 3 айны тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1-2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән ачык сервитутны гамәлгә ашыру турында килешү төзергә;

7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яки Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга


калмыйча, рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 11 июнендәге
1818 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Казан шәһәренең Мәскәү районында ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре




| Масштаб: 1:2000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:200106 | кадастр кварталы |
| 16:50:200106:876, 16:50:200106:1511, 16:50:200106:826, 16:50:000000:5481, 16:50:200106:196, 16:50:200106:85 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

_______________________________